Республика Татарстан
Зеленодольский муниципальный район
**Исполнительный комитет Большекургузинского сельского поселения**
Мирная ул., 41 с.Б. Кургузи, 422525
Тел:2-80-29
E-mail: Bkrg.Zel@tatar.ru

Татарстан Республикасы
Зеленодол муниципаль районы
**Олы Карауҗа авыл җирлеге башкарма комитеты**
Тынычлык ур., 41 О.Карауҗа ав., 422525
Тел:2-80-29
E-mail: Bkrg.Zel@tatar.ru

---

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ
# КАРАР

**29 ноябрь 2016 ел** **№29**

Олы Карауҗа авыл җирлегендә азкатлы шәхси торак төзелеше территориясеннән каты көнкүреш калдыкларын чыгару турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Каты көнкүреш калдыкларын чыгару буенча хезмәтләр күрсәтү Кагыйдәләрен раслау турында» 1997 елның 10 февралендәге 155 номерлы Карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Торак һәм коммуналь хезмәтләр күрсәткәндә халыкның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау системасының нәтиҗәлелеген арттыру чаралары турында» 2010 елның 19 февралендәге 85 номерлы карары нигезендә һәм чисталыкны тәэмин итү, йогышлар таралуны булдырмау һәм экологик хәлне яхшырту максатларында, **КАРАР ИТТЕ:**

1. Тәкъдим итү:

1.1. Олы Карауҗа авыл җирлеге территориясендә азкатлы төзелеш территориясеннән чүп чыгару буенча хезмәт күрсәтүче шәхси эшмәкәрләргә, аларның оештыру-хокукый формасына бәйсез рәвештә, әлеге территориядә яшәүче кулланучылар белән килешүләр төзергә.

1.2. Килешү төзегәндә каты көнкүреш калдыкларын җыю, чыгару һәм утильләштерү хезмәтләре күрсәтү бәясе бер кешегә аена 49,50 сумнан да артык түгел.

1.3. Теркәлгән гражданнар булмаган очракта, Олы Карауҗа авыл җирлегенең азкатлы торак йортларыннан каты көнкүреш калдыкларын җыю, чыгару һәм утильләштерү хезмәте күрсәтү бәясе йорт хуҗалыгыннан аена 49,50 сумнан да артмый.

2. Әлеге карар 2016 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. Әлеге карарны «Яшел Үзән» газетасында бастырып чыгарырга, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга (http://pravo.tatarstan.ru) Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмати сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru.).

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Олы Карауҗа
авыл җирлеге башлыгы М. Г. Шакиров